# Казан шәһәре Вахитов районы 12 нче татар телендә белем бирүчегимназиянең
# Гендер системасы буенча үсеш перспективлары

*И.А. Темиркаева, директор гимназии*

20 гасырның икенче яртысыннан башлап, алга киткән илләрдә, шул исәптән Россиядә дә психологлар, медиклар, социологлар хатын-кыз һәм ир-ат шәхесенең бар яктан да бик зур үзгәрешләр кичерүенә бик нык борчылу белдерәләр. Шунысы кызык: ир- ат сыйфатлары интенсив рәвештә хатын-кызларга күчә бара. Мондый җенес деградациясе-нең тән конституциясе дәрәҗәсендә генә түгел, ә бәлки тумыштан ук, ягъни гормональ- генетик яктан да булуын ассызыклыйлар.бу процессның нәтиҗәсе булып, үсмерләрдә ир-ат сыйфатын югалтуга бәйле рәвештә хезмәт потенциалы түбәнәйсә, хатын- кызлар бала үстерү, тәрбияләү потенциалын югалталар, гаиләләр ныклы какшый, төрле социал каршылыклар килеп чыга, шулар белән бергә милләтләр юкка чыга. Бу искиткеч зур проблема һәм аны чишү илнең дә, һәр милләтнең дә төп бурычы булып тора. Чөнки илнең, милләтләрнең киләчәген, цивилизациясен бары тик бар яктан камил шәхесләр генә булдыра ала.

Безнең алдыбызда килеп туган проблеманы чишүнең иң эффектлы юлларыннан берсе булып, кече яшьтән үк психик һәм физик яктан кызларны -хатын-кыз, малайларны- ир- ат итеп тәрбияләү тора. Әлбәттә, монда төп рольне гаилә уйный. Аннан соң мәктәп. Бу проблеманы фәнни яктан өйрәнү буенча Россиядә берникадәр тәҗрибә бар инде. Патша Россиясе вакытында ук кадет корпуслары, ирләр һәм хатын- кызлар гимназияләре эшләп килгән, шулай ук Советлар Союзында сугышка кадәр хәрби класслар, Суворов училищелары һәм менә соңгы ике унъеллыкта кайбер мәктәпләрдә параллель классларда кызларны, малайларны аерым укыту тәҗрибәсе. Юкка гына чит илләрдә ирләрне һәм хатын- кызларны аерым укыту тәрбияләү буенча мәктәпләр элитлы мәктәпләр дип аталмый.

Һәм, ниһаять, икенче буын федераль дәүләт гомуми белем стандартлары проектына, бик зур каршылыклар белән булса да, классларны җенес ягыннан комплектлауга игътибар ителгән. Алда сөйләнелгәннәргә нәтиҗә ясап, шуны әйтәсем килә. Балаларны аерым ягъни Гендер системасы буенча укытып, без ялгышмыйбыздыр.

Ә хәзер мин үзебезнеңТР сында бердәнбер татар телендә белем бирүче кызлар гимназиясенә тукталып китәсем килә. Гимназиядә белем бирү гуманитар фәннәрне тирәнтен өйрәнүгә юнәлтелгән, кызларыбыз өч тел өйрәнәләр. Татар телен өйрәнү, татар мохитендә тәрбияләү дәресләрдә генә түгел, класстан тыш чараларда да дәвам итә. Без әундый заманда яшибез, башка укучыларднан калышмый БДИ дә бирәсебез бар, шуңа күрә рус һәм математика фәннәреннән дә гимназиянең укыту планы мөмкинчелекләреннән чыгып, өстәмә дәресләр кертәбез. Күренекле галим Риза Фәхретдин -нең "**Балаларыгызны үзегез яшәгән заманга һәм башка заман өчен дә яраклы итеп укытыгыз" дигән** зирәк фикерен өлге итеп алабыз. Милләтләр язмышына бармак аша караган Россиядә үз милләтеңнең кызларын тәрбияләү өчен без нәрсә эшли алабыз? Белгәнегезчә, 1992 елдан бирле эшләп килгән бинабыз иске, эшләр өчен шартлар юк, ләкин шуңа карамастан кызларыбызны тәрбияләү өчен район базасында булган өстәмә белем бирү учреждениеләре белән даими рәвештә бәйләнештә тордык. Чөнки гимназиябез укучы кызларга төпле , системалы белем бирү белән беррәттән аларга хатын- кыз өчен кирәк булган һөнәрләргә өйрәтүне дә күз алдында тота. Тегү, чигү, бию, җыр,музыка, театр сәнгате белән шөгыльләнү өчен ярдәмне без алардан алдык. Ә телне өйрәнү, гореф -гадәтләребезне барлау, аларны онытмау, әхлак һәм башка тәрбия юнәлешләре дәресләрдә һәм класстан тыш чараларда алып барылды. Ислам диненә кагылышлы мәсь ләләр, әхлак тәрбиясе Р. Фәхретдин, К. Насыйри кебек мәгърифәтчеләребез өйрәтмәләренә таянып алып барыла. Безнең татар кызлары белемле, әхлаклы Һәр яктан камил, халкыбыз горурлыгы булырга тиешләр. Алай гына түгел, милләт аналары булырга тиешле затлар.

Яңа күчәчәк бинабыз, зур, якты. Белем бирү , һөнәргә өйрәтү, камил шәхес тәрбияләү өчен менә дигән бина. Кызларыбызны тормышта кирәк булачак яңадан- яңа, заманча һөнәрләргә ( дизайнер, флорист һ. б.) өйрәтергә мөмкин. ТР җитәкчелегенә, Т. Миңнуллинга бик зур рәхмәт. Кызларыбыз сәламәтлеген саклау өчен дә менә дигән шартлар тудырылган. Классларда укучылар санының 18 булуы да бик уңайлы, һәрберсенә игътибар җитәрлек булыр дип уйлыйбыз. Сезне, әлбәттә, безнең перспективаларыбыз, алдагы планнарыбыз кызыксындыра. Иң беренчесе, кызларныт тәрбияләү өчен фәнни база булдыру, авторлык программалары төзү. Аларны сынап карау кирәк. Бу эш гимназия ачылганнан бирле алып барыла, киләчәктә тагын да җәелдереп җибәрү генә сорала. Нинди генә яңа мәктәпләр ачма, әгәр дә анда педагогиканы, бала психологиясен яхшы белә торган, үз эшен һәм балаларны яраткан, заман технологияләрен үзләштергән киң эрудицияле кадрлар эшләми икән, бу мәктәпнең киләчәге юк. Гимназиябез базасында мондый укытучыларыбыз бар, ләкин яңа мәктәпкә алар күбрәк кирәк булачак. Мин шуларны күздә тотып әйтәм. Балаларны аерым укытуны оештырган белем бирү учреждениеләре белән тыгыз бәйләнештә тору, бу өлкәдә чит илдә булган тәҗрибәләрне өйрәнү . Бүгенге көндә балалар бакчалары төзелеп ята. Әгәр дә бер балалар бакчасын татар телендә белем бирүче гимназия базасына тапшырсалар, булачак татар кызларын тәрбияләү күпкә уңышлырак булыр иде дигән фикердә торам. Әлбәттә, телгә шундый караш яшәгән заманда гимназия тормышында авырлыклар күп булачак. Тормыш –көрәш. Ләкин без татар җанлы, татар рухлы сезнең кебек миллттәшләребез барында ярдәмсез калмабыз дип уйлыйм мин.